Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының егерме икенче утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары

2018 елның 22 ноябре № 173

«2017-2021 елларга Питрәч муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү турында» муниципаль максатчан программаны гамәлгә ашыру турында

«2017-2021 елларга Питрәч муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын гамәлгә ашыруның барышы турындагы докладын тыңлаганнан соң, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «2017-2021 елларга Питрәч муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын гамәлгә ашыру барышын канәгатьләнерлек дип танырга.

2. Район башкарма комитетына һәм авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- шәхси хуҗалыкларда мөгезле эре терлекләрнең баш санын саклап калу буенча эшне көчәйтергә;
- «РАЙПО» район кулланучылар кооперативы аша шәхси хуҗалыклар продукциясен сатып алу эшен оештырырга;
- Питрәч муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән республика һәм муниципаль программалар турында халык арасында аңлату эшләрен активлаштыру;
- Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Питрәч муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белән берлектә авылда шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм итү буенча республика һәм муниципаль программаларда катнашырга теләк белдергән гражданнарга һәртөрле консультатив ярдәм күрсәтергә.

3. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарга (халыкка игълан итәгә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Питрәч муниципаль районы Советының экология, табигатьтән файдалану, төзекләндерү һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов